**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О присуждении Государственной премии Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова в 2021 году

Рассмотрев предложения Комитета по присуждению Государственной премии Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова, **постановляю**:

1. Присудить Государственную премию Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова:

1) Аюпову Дамиру Алиевичу, кандидату технических наук, доценту кафедры технологии строительных материалов, изделий и конструкций федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский государственный архитектурно-строительный университет» – за значительный вклад в разработку научных основ получения стабильных битумполимерных дисперсий дорожного и гидроизоляционного назначения;

2) Саушину Илье Ирековичу, кандидату технических наук, старшему научному сотруднику лаборатории гидродинамики и теплообмена Института энергетики и перспективных технологий федерального государственного бюджетного учреждения науки «Федеральный исследовательский центр «Казанский научный центр Российской академии наук» – за значительный вклад в развитие методов оценки расхода многокомпонентных течений в нефтепроводах;

3) Цивильскому Илье Владимировичу, кандидату технических наук, доценту кафедры лазерных технологий федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский национальный исследовательский технический университет им. А.Н. Туполева – КАИ» – за значительный вклад в развитие физических основ технологии плазменной обработки металлопорошковых композиций для аддитивного производства и получение изделий наукоемкого машиностроения.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
28 июня 2021 года
№ УП-520

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2021 елда Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен тапшыру турында**

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен карап тикшергәннән соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә тапшырырга:

1) техник фәннәр кандидаты, «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең төзелеш материаллары, эшләнмәләре һәм конструкцияләре технологиясе кафедрасы доценты Әюпов Дамир Али улына – юл төзелешендә һәм судан саклауда кулланыла торган тотрыклы битум-полимер дисперсияләр ясауның фәнни нигезләрен эшләүгә зур өлеш кертүе өчен;

2) техник фәннәр кандидаты, «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе Энергетика һәм перспектив технологияләр институтының гидродинамика һәм җылылык алмашу лабораториясе өлкән фәнни хезмәткәре Саушин Илья Ирековичка – нефтьүткәргечләрдә күпкомпонентлы агымнарның сарыф ителүен бәяләү ысулларын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен;

3) техник фәннәр кандидаты, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе лазер технологияләре кафедрасы доценты Цивильский Илья Владимировичка – аддитив җитештерү һәм машиналар төзелешендә фән казанышларына нигезләнгән эшләнмәләр ясау өчен металл комыннан композицияләрне плазма белән эшкәртү технологияләренең физик нигезләрен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 28 июнь
№ ПУ-520